**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 8 апрель № 206

г. Казань

2016-2020 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерү концепциясен раслау турында

Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымтада бирелә торган 2016-2020 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерү концепциясен расларга.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына мәнфәгатьле министрлыклар һәм ведомстволар белән берлектә һәм Татарстан Республикасының Кулланучылар җәмгыятьләре оешмалары берлеге катнашында 2016 елның 1 декабренә кадәр әлеге карар белән расланган Концепцияне тормышка ашыру буенча чаралар планын эшләргә һәм раслау өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

3. Әлеге караның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 8 апрель, 206 нчы
карары белән расланды

**2016-2020 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерү концепциясе**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге 2011-2015 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерү концепциясендә (алга таба – Концепция) Татарстан Республикасы кулланучылар кооперациясен үстерүнең төп максатлары һәм бурычлары, проблемаларның эчтәлеге һәм аларны хәл итү, шулай ук Концепцияне гамәлгә ашыру механизмы формалаштырылды. Концепцияне гамәлгә ашыру кулланучылар кооперациясенең тотрыклы, алга таба үсешен, социаль-икътисадый проблемаларны хәл итүдә кулланучылар кооперациясе оешмаларының ролен күтәрүне һәм республиканың азык-төлек белән тәэмин итү өлкәсендә үз-үзен тәэмин итүенә ирешүне тәэмин итәргә тиеш.

1.2. Әлеге Концепциядә кулланучылар кооперациясе дип «Россия Федерациясендә кулланучылар кооперациясе (кулланучылар җәмгыятьләре, аларның берлекләре) турында» 1992 елның 19 июнендәге 3085-I номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә төзелә һәм эш итә торган кулланучылар җәмгыятьләре һәм аларның берлекләре системасы аңлашыла.

1.3. Республиканың кулланучылар кооперациясе әзерләү, эшкәртү һәм сәүдә эшчәнлеген башкаручы, авыл халкына социаль һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтүче мөһим система булырга тиеш.

2. Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерүнең максатлары һәм бурычлары

2.1. Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерүнең төп максатлары булып авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне сизелерлек арттыру һәм авыл халкының тормыш дәрәҗәсен күтәрү тора.

2.2. Концепция хәл итүгә юнәлтелгән төп бурычлар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

кулланучылар кооперацияләре тарафыннан авыл хуҗалыгы продукциясе сатып алу күләмнәрен арттыру;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең эш активлыгын күтәрү;

кулланучылар кооперативлары базасында икътисадый яктан нәтиҗәле, инвестицияләү ягыннан кызыклы авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү һәм эшкәртү системасы булдыру;

кулланучылар кооперациясенә ярдәм итүнең мәгълүмати системасын булдыру;

кулланучылар кооперациясе кадрлар потенциалын һәм һөнәри белем бирүне үстерү.

## 3. Проблемаларның эчтәлеге һәм аларны хәл итү юллары

3.1. Республикада яшәүчеләрнең шәхси ярдәмче хуҗалыкларында әзерләнә торган авыл хуҗалыгы продукциясе ресурсларын үзләштерү – кулланучылар кооперациясенең әзерләү тармагын үстерүнең төп бурычы. Әзерләү тармагы эше күрсәткечләре барлык кулланучылар кооперациясе эшчәнлегенең барометры булып тора.

Әзерләү эшчәнлеген үстерүгә тоткарлык ясаучы төп проблемалар түбәндәгеләр:

сатып алынган авыл хуҗалыгы продукциясен һәм кыргый үсүче чималны сатуның бердәй системасы булмау;

продукция сатып алу һәм аны саклау матди-техник базасының үсеше өчен әйләнештәге чараларның җитәрлек булмавы;

сатып алынучы авыл хуҗалыгы продукциясенең сыйфаты төрле булу;

әзерләү тармагында махсус кадрлар булмау.

Булган проблемаларны исәпкә алып, кулланучылар кооперациясенең әзерләү эшчәнлеген үстерүдә өстенлекле юнәлешләр булып түбәндәгеләр тора:

авыл хуҗалыгы продукциясен әзерләү һәм саклауның матди-техник базасын үстерү, гамәлдә булган яшелчә һәм бәрәңге саклагычларны торгызу һәм яңаларын төзү;

авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел эшкәртү, саклау һәм сату өчен булган производство һәм сәүдә куәтләре потенциалыннан файдалану;

терлек чалу пунктларын торгызу һәм югары җитештерүчән файдалану;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре өчен базарлардагы сәүдә урыннарын булдыру исәбенә сатып алуларны сату системасы белән интеграцияләү;

шәхси ярдәмче хуҗалыклар ияләренә яшелчәләр һәм башка авыл хуҗалыгы культураларын үстерүгә орлыклар бүлеп бирү һәм аннары үстергән уңышны сатып алу юлы белән ярдәм күрсәтү;

әзерләү эшчәнлеге буенча кадрлар әзерләү;

икътисадый актив, эш белән тәэмин ителмәгән халыкны дару-техник һәм кыргый үләннәр чималын җыю эшчәнлегенә җәлеп итү.

3.2. Кулланучылар кооперациясенең җитештерү эшчәнлеген характерлаучы төп проблемалар түбәндәгеләр:

техник һәм технологик тәэмин итү ягыннан түбән дәрәҗә;

эшләп чыгарылучы продукция һәм күрсәтелүче хезмәтләрнең ассортименты җитәрлек булмау.

кулланучылар җәмгыятьләре һәм кооперативларының җитештерү эшчәнлеген, түләүле хезмәтләр күрсәтүне һәм авыл халкына көнкүреш хезмәте күрсәтүне үстерүнең өстенлекле юнәлешләре булып түбәндәгеләр тора:

кирәк булганда, предприятиеләрне әзер продукцияне сату өчен бердәй логистик схемаларга берләштерү;

әзерләү һәм сәүдә эшчәнлеге системасын кооператив производствосы белән интеграцияләү;

булган производстволарны модернизацияләү һәм яңаларын төзү,

кооператив производствосының энергия куллануын киметү проектларын гамәлгә ашыру;

гамәлдәге җитештерү куәтләрен ким дигәндә 80 процент дәрәҗәсендә үзләштерү (эшләтү);

продукциянең сыйфаты халыкара системасын һәм җитештерү белән идарә итү системасын кертү;

сәүдә челтәрендә продукцияне тәкъдим итү өчен кооператив сәүдә билгеләрен кертү;

кулланучылар кооперациясенең күргәзмә чараларында һәм ярминкәләрдә катнашуын тәэмин итү;

җитештерү цехларында эшләү өчен белгечләрне яңа технологияләргә өйрәтү;

җитештерүгә һәм товарларны базарларда тәкъдим итүгә ярдәмнең бердәй мәгълүмати системасын формалаштыру;

ерактагы торак пунктларда халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтүнең күчмә формасын, шулай ук челтәр кибетләрендә заказчының өенә барып көнкүреш хезмәте күрсәтүгә заказлар алу аша эшкә кертү;

ветераннарга, инвалидларга, халкының социаль яклanмаган төркемнәренә хезмәт күрсәтүгә иҗтимагый һәм бүтән оешмалар белән шартнамәләр буенча үзара бәйләнешләр урнаштыру;

көнкүреш хезмәте күрсәтү тармагын үстерү буенча дәүләт һәм ведомство максатчан программаларын тормышка ашыруда катнашу;

кулланучыларның түләүгә сәләтле соравын исәпкә алып, кирәкле хезмәт күрсәтүләргә ихтыяҗны билгеләү буенча даими мониторинг үткәрү.

3.3. Сәүдә – кулланучылар кооперациясе эшчәнлегенең төп юнәлешләренең берсе. Кулланучылар кооперациясе сәүдә эшчәнлегенең төп билгеләнеше кооперативлар тарафыннан әзерләнгән һәм эшкәртелгән продукциянең кулланучыларга, пайчыларга, кооператив әгъзаларына җиткерелүеннән гыйбарәт. Кулланучылар кооперациясенә шулай ук барырга кыен, халык аз булган пунктларда яшәүчеләрне беренче кирәкле товарлар һәм азык-төлек белән тәэмин итү өчен җаваплылык йөкләнгән

Кулланучылар кооперациясе сәүдә эшчәнлеге сизелерлек үзенчәлеккә ия, алар кооперациянең үсешендә төп юнәлешләрне билгеләгәндә исәпкә алынырга тиеш:

ул авыл халкының байтак өлешенә хезмәт күрсәтә;

үз продукциясен җитештерү исәбенә сәүдә ихтыяҗларын өлешчә тәэмин итү өчен мөмкинлекләргә ия.

Шуны билгеләп үтәргә кирәк:

кибетләрнең шактый өлеше, бигрәк тә халкы 100 кешедән ким булган торак пунктларда зыянга эшли һәм нигездә социаль функцияне башкара;

күп кенә сәүдә нокталары мөмкин булган логистик бүлү үзәкләреннән шактый ерак урнашкан.

Кулланучылар кооперациясенең сәүдә эшчәнлеген үстерүдә төп өстенлекләре түбәндәгеләр булырга тиеш:

сатыла торган продукциянең, күрсәтелә торган хезмәтләрнең ассортиментын киңәйтү;

сәүдә объектларын, аларда хезмәт күрсәтүне бизәүнең унификацияләнгән стандартларын, сәүдә челтәрләренең бердәй брендларын булдыру;

сәүдәнең яңа юнәлешләреннән файдалану («Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәре аша товарларга заказ бирү һ.б.);

сәүдә процессларын автоматлаштыру (товарлар килүне һәм сатуны исәпкә алыу);

район үзәкләреннән ерактагы, зур булмаган торак пунктлар өчен зур социаль әһәмияткә ия сәүдә кооперативларына булышлык күрсәтү;

үзе җитештергән продукцияне һәм беренче әһәмияттәге товарларны сату өчен күчмә сәүдәне үстерү;

субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме сыйфатында алынган автолавкаларны нәтиҗәле файдалануны күчмә сату графигын үтәүне тикшерүләр, GPS-навигаторлар урнаштыру юллары белән тикшерүне һәм исәпкә алуны тәэмин итү;

инвестиция ресурсларын, кулланучылар җәмгыятьләре һәм кооператив пайчыларының һәм әгъзаларының әйләнештә булмаган акчаларын җәлеп итү.

3.4. Җәмәгать туклануын оештыру кулланучылар кооперациясе эшчәнлегенең социаль әһәмияткә ия юнәлешләренең берсе булып тора. Күп хезмәтләр эксклюзив характерда һәм аеруча авыл районнарында бик таләп ителә. Моның белән бергә җәмәгать туклануы – аеруча катлаулы һәм күп көч таләп итә торган тармакларның берсе. Җәмәгать туклануы системасын үстерүнең максаты – кулланучылар кооперациясендә халык ихтыяҗларын канәгатьләндерә торган, икътисади яктан расланган һәркем алырлык һәм сыйфатлы җәмәгать туклануы системасын үстерү.

Җәмәгать туклануы системасын үстерүнең төп бурычлары:

җәмәгать туклануы предприятиеләрен булдыру һәм замана базары үсеше юнәлешләре нигезендә аларның форматын оптимальләштерү;

җәмәгать туклануының башка оешмалары өчен характерлы булмаган үзенчәлекле җәмәгать туклануының аерым предприятеләрен үстерү;

кулланучылар кооперациясенең җәмәгать туклануы объектлары базасында кулинар, кондитер эшләнмәләре һәм полуфабрикатлар җитештерүне үстерү;

ваклап сату челтәрләре аша гамәлгә ашыру хисабына продукция сату базарларын киңәйтү;

районның һәр мәктәпкәчә белем бирү оешмасын һәм гомуми белем бирү оешмасын җәмәгать туклануы предприятиеләре белән колачлау;

үз продукциясен китереп бирү буенча тендерларда катнашу;

түбәндәге критерияләр буенча халыкка күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген оптимальләштерү: комплекслылык, ихтыяҗ булу, эксклюзив булу (башка субъектлар күрсәтми торган хезмәтләр күрсәтү мөмкинлеге) һәм конкурентлылык сәләте;

матди техник базаны үстерү һәм камилләштерү;

технологик процессларны механикалаштыру һәм автоматлаштыру, ризык җитештерү һәм сату өчен югары җитештерүчәнлекле җиһазларны эшкә кертү, яңа техниканы нәтиҗәле файдалану, гамәлдәге җайланмаларны яңарту, җитештерү процессларын компелксլы механикалаштыру һәм автоматлаштыру;

продукция сыйфатын тәэмин итү һәм тикшерүдә тоту системасын булдыру, нәтиҗәле маркетинг стратегиясен эшләү;

кулланучыларның төрле группаларына ориентлашкан туклану предприятиеләре челтәрләрен үстерү, аерым алганда милли һәм йола ашамлыкларын исәпкә алган, хезмәт күрсәтүләрнең киң комплексын күрсәтеп, корпоратив, гаиләнең (өлкәннәрнең

буш вакытын оештыру һәм балалар өчен уен бүлмәләре оештыру белән), яшьләрнең буш вакытын оештыруны, мәдәни һәм күңел ачу чаралары үткәрүне тәэмин итә торган;

ризык әзерләүнең индустриаль ысулларын кулланучы ризык әзерләү буенча белгечләрнең өйгә килүе һәм ризыкны кулланучылар заказлары буенча китереп бирү;

өстәмә хезмәтләр күрсәтә торган җәмәгать туклануының юл буен нокталары, балалар кафелары челтәрен булдыру һәм үстерү;

«Кулинария» кибетләр челтәрен үстерү, аларда үз продукциясен киң ассортиментта җиткерә һәм сата торган кечкенә икмәк пешерү, татлы ашамлыклар әзерләү йортлары, пәрәмәч цехлары булдыру.

3.5. Кулланучылар җәмгыятьләре һәм кооперативларының күптармаклы эшчәнлеген кадрлары белән сыйфатлы тәэмин итү системаны үстерүнең төп резервы булып тора.

Кулланучылар кооперациясенең кадрлар потенциалын үстерү өстенлекләренә түбәндәгеләр карый:

кулланучылар җәмгыятьләре һәм кооперативлары хезмәткәрләре нәтиҗәлелегеннән чыгып бүләкләү, аларны хезмәткә мотивлаштыру системасын булдыру;

сәүдәдә, җитештерүдә, продукцияне әзерләү һәм сатуда актуаль мәсьәләләрне хәл итүгә яшь хезмәткәрләрне җәлеп итү, аларның әзерләүне, яңадан әзерләүне һәм квалификацияләрен күтәрүне тәэмин итү, аларны торак белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру;

һөнәри белем бирү оешмасында һәм югары белемнең белем бирү оешмасында белгечләр әзерләүгә заказ формалаштыру, остазлыкны һәм стажировканы үстерү.

3.6. Кулланучылар кооперациясен үстерүдә кооперациянең өстенлекләре турында авыл халкына тулы мәгълүмат бирмәү, кооперативлар эшчәнлегенә мәгълүмати ярдәмнең системалы һәм киң колачлы булмавы төп тоткарлыклардан булып тора. Барлык бу проблемалар кулланучылар кооперациясенең идеологиясендә салынган системалылык өстенлекләреннән тулы файдаланырга мөмкинлек бирми

Кулланучылар кооперациясенә мәгълүмат белән ярдәм итүне үстерүнең өстенлекләре түбәндәгеләр булырга тиеш:

республиканың агросәнәгать комплексының мәгълүмат-консультация хезмәте системасын кулланучылар кооперациясен үстерү мәсьәләләренә җәлеп итү;

кулланучылар җәмгыятьләре һәм кооперативлары эшчәнлеген мәгълүматлаштыру, бу аларны бердәм мәгълүмат системасына берләштерергә, продукция сатуның яңа каналларын табарга, яңа техника һәм технологияләр, яңа продукт турында мәгълүматны үз вакытында алырга мөмкинлек бирәчәк;

сәүдә процессларын автоматлаштыруны кертү (товарлар керүнең һәм сатуның исәбен алу).

3.7. Кулланучылар кооперациясенең бер система буларак нәтиҗәле үсешенә аеруча сизелерлек каршылыклар булып түбәндәгеләр тора:

бер төркем кулланучылар җәмгыятьләре һәм кулланучылар кооперациясе оешмаларының үзара бәйләнешләре һәм бергәләп үсеше булмау;

кулланучылар кооперациясенең зурлыклары һәм составы буенча бер төрле булмаган, төрле оештыру-хокук формасындагы оешмалары булу;

пайчыларның кулланучылар кооперациясе эшчәнлегендә катнашырга мәнфәгатьләре булмау.

Моның белән бергә пайчылар белән үзара багланышлар системасы пайчының кулланучылар җәмгыятенә карата лояль булуы исәбеннән тәэминителергә тиеш, сәүдә эшчәнлеге өлешендә – товарларны кулланучылар кооперациясе кибетләреннән сатып алу нигезендә, әзерләү эшчәнлеге өлешендә – артык продукцияне даими рәвештә кулланучылар кооперациясе оешмаларына бирү нигезендә.

Кулланучылар җәмгыятьләренең хуҗалык эшчәнлегендә, иҗтимагый кооператив эшчәнлекнең төрле аспектларын планлаштырганда, агымдагы тикшерүдә тотканда, эш нәтиҗәләрен чыгарганда һәм кооператив мөлкәтен саклауны тәэмин иткәндә пайчының ролен күтәрү зарур

Барлык пайчыларның электрон исәбен алып бару һәм кулланучылар кооперациясе оешмаларына яңа пайчыларны җәлеп итү буенча чаралар комплексын эшләү кирәк.

3.8. Кулланучылар кооперациясе оешмаларының финанс тотрыклылыгын күтәрү.

Кулланучылар кооперациясе оешмаларының финанс тотрыклылыгын күтәрүнең төп юнәлеше булып алар тарафыннан финанс стратегиясен формалаштыру һәм тормышка ашыру булырга тиеш.

Финанс сәясәте оешмаларның үз мөмкинлекләрен реаль бәяләүгә, шулай ук өченче затлардан финанс ресурслары җәлеп итүгә нигезле якын килүгә (заемнар, кредитлар, инвестиция ресурслары) һәм операцион эшчәнлектә капиталь салуларның куркынычын киметүгә нигезләнгән финанс планлаштыруы белән ныгытылган тигез үсешен тәэмин итәргә тиеш.

Кулланучылар кооперациясе оешмаларының финанс тотрыклылыгын күтәрү максатларында түбәндәгеләр зарур:

кулланучылар кооперациясе оешмасының эшчәнлеге туктауны булдырмау (шул исәптән банкротлык, мәҗбүри бетерү һ.б. сәбәпләр буенча);

тотрыклы финанс сәясәте һәм стратегик программалар һәм проектларны тормышка ашыру өчен финанслау чыганакларының җитәрлек булуы нигезендә эшләүнең һәм үсешнең тотрыклы булуын тәэмин итү;

инвестиция, финанс һәм салым сәясәтен эшләү һәм тормышка ашыруга бердәм якын килүне һәм методологиясен булдыру.

3.9 Кулланучылар кооперациясе үсешенең барлык этапларында да кулланучылар кооперациясе мөлкәтен саклау, нәтиҗәле файдалану мәсьәләсе актуаль булып кала. Моның белән бәйле Татарстан Республикасы кулланучылар җәмгыятьләре берлегенең Кооператив милкен саклауны тәэмин итү һәм пайчылар белән эшләү буенча комиссиясен төзү кирәклеге барлыкка килде. Комиссия халкы саны 3 мең кешедән артмаган торак пунктларында урнашкан кооператив мөлкәтен алу мөмкинлеге белән материалларны карап тикшерергә тиеш (халык саны 3 мең кешедән артканда Россия Федерациясе Үзәк кулланучылар җәмгыятьләре берлегендә карап тикшерелә). Мөлкәтне алу мөмкинлеге турында карар беренче чиратта пайчылар җыелышында карап тикшерелергә тиеш (аларның кимендә ¾ е булганда). Барлык яңа төзелгән кулланучылар җәмгыятьләрен, район кулланучылар җәмгыятьләре, кулланучылар кооперативлары һәм кулланучылар берлекләре банкротлыгыннан соң төзелгәннәрен

дә кертеп, Татарстан Республикасы кулланучылар җәмгыятьләре берлеге составына кертүне тәэмин итә торганчаралар комплексын эшләү зарур.

## 4. Концепцияне тормышка ашыру механизмы

4.1. Концепцияне тормышка ашыру түбәндәге юнәлешләр буенча планлаштырыла:

Татарстан Республикасы авыл җирлегендә бөтен җирдә сәүдә хезмәте күрсәтү һәм продукцияне сатып алу, эшкәртү һәм сату буенча халыкка хезмәт күрсәтү кулланучылар кооперациясе оешмаларын төзү;

кулланучылар җәмгыятьләре, кооперативларына һәм кулланучылар кооперациясе оешмаларына авыл хуҗалыгы җитештерүен техник һәм технологик яңартуга чыгымнарның бер өлешен кайтару;

яшелчә һәм бәрәңге саклагычларны капиталь төзәтү буенча эшләр башкару белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү;

терлекчелек продукциясенең аерым төрләрен сатып алу, эшкәртү һәм сату буенча авыл хуҗалыгы әзерләү-куллану кооперативларына, әзерләүче оешмаларга һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә чыгымнарының бер өлешен кайтару;

кулланучылар җәмгыятьләре һәм кооперативлары тарафыннан финанс арендасы (лизинг) шартнамәләре (ЛИЗИНГ-ГРАНТ) буенча җиһазлар сатып алуга дәүләт ярдәме алу;

кулланучылар җәмгыятьләрен һәм кооперативларын электрон сәүдә аша дәүләт сатып алуларында катнашырга җәлеп итү;

кулланучылар җәмгыятьләре һәм кооперативлары тарафыннан республика базарларында сөт, ит һәм башка авыл хуҗалыгы продукциясе белән күпләп сатуны оештыру;

Татарстан Республикасы муниципаль районнарында мәгълүматый, хокукый, методик хезмәтләр күрсәтүче мәгълүмат-консультация үзәкләре челтәрен үстерү.

---